Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

КАРАРЫ

«19» февраль 2019 ел № 19

“ТР, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ф. Кәрим урамы буенча түбән басымлы газүткәргечне күчерү " объекты өчен территорияне планлаштыру һәм межалау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьясы нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планлаштыру структурасы элементларын билгеләү максатларында,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. "ТАТИНВЕСТГРАЖДАНПРОЕКТ" дәүләт унитар предприятиесенә үз акчалары исәбеннән “ТР, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ф. Кәрим урамы буенча түбән басымлы газүткәргечне күчерү " объекты өчен территорияне планлаштыру һәм межалау проектын әзерләүгә керешергә тәкъдим итәргә. (1 нче кушымта)

2. «Әлмәт муниципаль районы һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе нигезендә әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Мөхәммәтҗанов А.А. ка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 19 феврале 19 номерлы карары белән расланган 1 нче кушымта

“ТР, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ф. Кәрим урамы буенча түбән басымлы газүткәргечне күчерү " объекты өчен территорияне планлаштыру һәм межалау проект чикләре




Башкарма комитет җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары А.А. Мөхәммәтҗанов